ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО АРХИВНОМУ ДЕЛУ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ АРХИВ ЭШЕ БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПРИКАЗ**

**_19.09.2024_________** **№__150-од_____**

Татарстан Республикасы Архив эше буенча дәүләт комитетының «Татарстан Республикасы Архив эше буенча дәүләт комитеты идарәсендәге Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычны түләтүнең өметсез булуын тану турында карар кабул итү тәртибен раслау хакында» 2023 елның 16 ноябрендәге 174-од номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Архив эше буенча дәүләт комитеты идарәсендәге Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычны түләтүнең өметсез булуын тану турында карар кабул итү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Архив эше буенча дәүләт комитетының «Татарстан Республикасы Архив эше буенча дәүләт комитеты идарәсендәге Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычны түләтүнең өметсез булуын тану турында карар кабул итү тәртибен раслау хакында» 2023 елның 16 ноябрендәге 174-од номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Архив эше буенча дәүләт комитеты идарәсендәге Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычны түләтүнең өметсез булуын тану турында карар кабул итү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктның 2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) «Бөлгенлек (банкротлык) турында» 2002 елның 26 октябрендәге 127-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә гражданга, индивидуаль эшкуарга карата банкротлык процедурасы тәмамлану - күрсәтелгән Федераль закон нигезендә бурычларын түләүдән азат ителгән бюджетка түләүләр буенча бурыч өлешендә;»;

2 пунктның 3 пунктчасын үз көчен югалткан дип танырга;

2 пунктның 5 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5) штрафка тарту рәвешендә җәза алуга хөкем ителгәннәргә карата амнистия яисә ярлыкау турында актлар куллану яисә суд тарафыннан бюджет керемнәре администраторының бюджетка түләүләр буенча бурычларны түләтү мөмкинлеге югалуы өчен, шул исәптән аны түләтүнең билгеләнгән срогы чыгуга бәйле рәвештә, нигез булган карар кабул ителү;»;

2 пунктның 6 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6) Үтәүче суд приставы тарафыннан «Үтәтү эше турында» 2007 елның 2 октябрендәге 229-ФЗ номерлы Федераль законның 46 статьясындагы 1 өлешенең 3 яисә 4 пунктында каралган нигез буенча башкарма документны түләтүчегә кире кайтарып биргәндә үтәтү эше тәмамлану турында карар чыгарылу, әгәр күләме банкротлык турындагы эш буенча үтәтү башлау өчен бөлгенлек (банкротлык) турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән бурычлыга карата таләпләр күләменнән артмаган бурыч барлыкка килгән көннән алып биш елдан артык узса;»;

2 пунктта түбәндәге эчтәлекле пунктча өстәргә:

«$6^1$) бурычлыны банкрот дип тану турында гаризаны кире кайтару яисә банкротлык турындагы эштә кулланыла торган процедураларны уздыруга суд чыгымнарын капларлык акча булмау сәбәпле банкротлык турындагы эшне үтәтүне туктату турында акт кабул итү;»;

4 пунктның 3 пунктчасында:

дүртенче абзацта «2 пунктның 3 пунктчасында» сүзләрен «2 пунктның 2 пунктчасында» сүзләренә алмаштырырга;

җиденче абзацта «6 пунктчада» сүзләреннән соң «, 7 пунктчада» сүзләрен өстәргә;

сигезенче абзацта «6 пунктчасының өченче абзацында» сүзләрен «$6^1$ пунктчасында» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле $10^1$ пункт өстәргә:

«Комиссия утырышы йомгаклары буенча Тәртипнең 11 пунктындагы икенче абзацында күрсәтелгән очракта утырыш уздырылган көннән алып ун эш көне эчендә Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычны түләтүне өметсез дип тану турында карар проекты әзерләнә.»

Тәртипнең 11 пунктында «ун» сүзен «унбиш» сүзенә алмаштырырга;

Тәртипнең 11 пунктындагы унынчы абзацында «рәисе» сүзен «рәислек итүче» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле унөченче пункт өстәргә:

«Тәртипнең 11 пунктының өченче абзацында күрсәтелгән очракта Комиссия утырышы беркетмәсендә Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычны түләтүне өметсез дип тану өчен нигезләрнең булмавы турында мәгълүмат күрсәтелә. Беркетмә утырышта рәислек итүче һәм Комиссия секретаре тарафыннан имзалана һәм рәискә игътибарга алу өчен җибәрелә.».

Рәис Г.З. Габдрахманова